**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕОШНЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422646, с. Большой Ошняк,
ул. Г.Тукая, дом 28а

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ӘШНӘК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422646, Олы Әшнәк авылы,
Г.Тукай урамы, 28а йорт,

Тел.: (84361) 27738, факс: (84361) 27738, e-mail:Bosn.Rs@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**20 декабрь, 2021 ел** **Олы Әшнәк авылы** **№ 14**

2022 елга Олы Әшнәк авыл җирлеген төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү хәвеф-хәтәрләрен профилактикалау программасын раслау турында

“Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 8.2 маддәсе һәм 9 маддәсенең 11.3 өлеше һәм “Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан мәҗбүри таләпләрне, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларны профилактикалау буенча чараларны оештыруга һәм гамәлгә ашыруга карата гомуми таләпләрне раслау турында” 2018 елның 26 декабрендәге 1680 номерлы РФ Хөкүмәте карары нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елга Олы Әшнәк авыл җирлеген төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү хәвеф-хәтәрләрен профилактикалауның кушыта итеп бирелә торган программасын расларга.

2. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Олы Әшнәк авыл җирлегенең Олы Әшнәк авылы, Г.Тукай урамы, 28а йорт; Кече Әшнәк авылы, Кызыл Армия урамы, 32а йорт адреслары буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Башлыгы Р.А.Хөснетдинова

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Олы Әшнәк авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2021 елның
20 декабрендәге 14 номерлы
карары белән расланды

## 2022 елга Олы Әшнәк авыл җирлеген төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү хәвеф-хәтәрләрен профилактикалау программасы

2022 елга Олы Әшнәк авыл җирлеген төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль кысаларында закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү хәвеф-хәтәрләрен профилактикалау программасы (алга таба – Программа) "Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында" 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законның 44 маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2021 елның 25 июнендәге 990 номерлы "Закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар салу) хәвеф-хәтәрләрен профилактикалау программасының контроль (күзәтчелек) органнары тарафыннан эшләү һәм раслау Кагыйдәләрен раслау турында"гы карары нигезендә эшләнде һәм төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне (алга таба – муниципаль контроль) гамәлгә ашырганда закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар салу) хәвеф-хәтәрләрен профилактикалау (кисәтү) чаралары комплексын күздә тота.

Программа түбәндәге бүлекләрдән тора:

1. Контроль төрен гамәлгә ашыруның агымдагы торышын анализлау, тикшерү (күзәтчелек) органының профилактик эшчәнлегенең агымдагы үсешен тасвирлау, Программа хәл итүгә юнәлтелгән проблемаларның сыйфатламасы;
2. Программаны тормышка ашыруның максатлары һәм бурычлары;
3. Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү вакытлары (периодиклыгы);
4. Программаның нәтиҗәлелек һәм эффектлылыгы күрсәткечләре.

### 1 бүлек. Контроль төрен гамәлгә ашыруның торышын анализлау, тикшерү (күзәтчелек) органының профилактик эшчәнлегенең агымдагы үсешен тасвирлау, Программа хәл итүгә юнәлтелгән проблемаларның сыйфатламасы;

Муниципаль контроль предметы булып тора:

- юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар (алга таба – контрольдә тотылучы затлар) тарафыннан җирләрдән файдалану өлкәсендәге Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән, бозган өчен Россия Федерациясе законнарында административ җаваплылык каралган мәҗбүри таләпләрне үтәү (алга таба – мәҗбүри таләпләр);

- контрольдә тотылучы затлар тарафыннан рөхсәт документларындагы таләпләрне үтәү;

- үтәлеше Россия Федерациясе законнары нигезендә зарури булган документлар таләпләрен үтәү;

- контроль чаралар нәтиҗәләре буенча кабул ителә торган карарларны үтәү.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда түбәндәгеләр үткәрелергә мөмкин:

-профилактик (кисәтү) чаралары;

- тикшерү чаралары.

Төзекләндерү өлкәсендә контроль предметы булып юридик затлар, шәхси эшкуарлар, гражданнар тарафыннан җирлекне төзекләндерү кагыйдәләрен, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү тора.

2020-2021 елларда контрольдә тотылучы субъектларга карата планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрелмәгән.

Тикшерелә торган затлар тарафыннан законнарның мәҗбүри таләпләрен үтәүгә, контрольдә тотыла торган затларны намуслылыкка мәҗбүр итүгә юнәлдерелгән профилактик чаралар үткәрү тулаем вәзгыятьнең яхшыруына, контрольдә тотылган затларның җаваплылыгын күтәрүгә, ачыкланган мәҗбүри таләпләрне, Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларда, муниципаль норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләрне бозуларның санын киметүгә китерәчәк.

## 2 бүлек. Программаны тормышка ашыруның максатлары һәм бурычлары

2.1. Программаның төп максатлары булып тора:

- барлык контрольдә тотылган затлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрне намуслы үтәүне стимуллаштыру;

- мәҗбүри таләпләрне бозуга һәм (яисә) закон белән саклана торган кыйммәтләргә зыян китерергә (зарар салырга) сәләтле шартларны, сәбәпләрне һәм факторларны бетерү;

- мәҗбүри таләпләрне контрольдә тотылучы затларга җиткерү өчен шартлар тудыру, аларны үтәү ысуллары турында мәгълүматлылыкларын (хәбәрдарлыкларын) арттыру.

2.2. Программаның профилактик чараларын үткәрү түбәндәге бурычларны хәл итүгә юнәлдерелгән:

- закон тарафыннан саклана торган кыйммәтләргә зыян китерү (зарар салу) хәвеф-хәтәрен кисәтү системасын ныгыту;

- дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары җитәкчеләренең, юридик затларның, шәхси эшкуарларның һәм гражданнарның хокукый аңын һәм хокукый культурасын арттыру;

- гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүнең мөмкин булган куркынычын бәяләү, аны киметүгә ярдәм итә торган профилактик чараларны эшләү һәм тормышка ашыру;

- гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зыян китерүгә куркыныч янау факторларын, мәҗбүри таләпләрне бозуга китерә торган сәбәпләрне һәм шартларны ачыклау, янауларны бетерү яисә киметү ысулларын билгеләү.

## 3 бүлек. Профилактик чаралар исемлеге, аларны үткәрү вакытлары (периодиклыгы)

3.1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә автомобиль транспортында, шәһәр җир өсте электр транспортында һәм юл хуҗалыгында муниципаль контроль турындагы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә түбәндәге профилактик чаралар үткәрелә:

*а) мәгълүмат җиткерү;*

*б) хокук куллану практикасын гомумиләштерү;*

*в) искәртү игълан итү;*

*г) консультация бирү;*

*д) кисәтү визиты.*

3.2. Үткәрү вакытларын (периодиклыгын) күрсәтеп, профилактик чаралар исемлеге, аларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затлар Программага кушымтада күрсәтелгән.

## 4. Программаның нәтиҗәлелек һәм эффектлылыгы күрсәткечләре

4.1. Программаның максатчан индикаторлары һәм сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

мәҗбүри таләпләрнең эчтәлеге турында контрольдә торучы субъектларның мәгълүматлылыгы;

мәҗбүри таләпләрнең аңлаешлыгы, аларны контрольдә торучы субъектлар һәм муниципаль контроль органының вазыйфаи затлары тарафыннан бер мәгънәдә аңлату;

кабул ителгән һәм әзерләнә торган мәҗбүри таләпләр турында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылган мәгълүматның һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итү буенча контрольдә торучы субъектларның канәгатьлеге;

тикшерүләр уздырганда контрольдә торучы субъектларның хокуклары, аларны уздыру тәртибе турында контрольдә торучы субъектларның мәгълүматлылыгы;

программадагы профилактик чараларын үтәү.

Программаны тормышка ашыруның микъдар күрсәткече булып уздырылган профилактик чаралар саны тора.

4.2. Календарь ел нәтиҗәләре буенча программаның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен, әлеге программада максатларга ирешүне исәпкә алып, сан күрсәткечләре билгеләнә:

| № п/п | Индикатор | Күрсәткечләр |
|---|---|---|
| 1 | Җир законнарының мәҗбүри таләпләрен үтәү мәсьәләләре буенча контрольдә торучы затларга мәгълүмат бирү буенча сайтта урнаштырылган мәкаләләр саны | 2 |
| 2 | Консультация бирү | 12 |